| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |
| пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740 | Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740 |

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ ПР-239 02.11.2024 №_____

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы «Актаныш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә раслау хакында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 21 мартындагы ПР-51 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2024 елның 07 октябрендәге 03-12/7086 номерлы хаты нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль бюджет учреждениесе, Актаныш муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең 4 пунктына үзгәреш кертергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль бюджет учреждениесе, Актаныш муниципаль районы «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
| --- | --- | --- |
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органы) структур бүлекчәсе булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 33 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары, баш | 31 500 | |

| | | |
|---|---|---|
| бухгалтер | | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 31 500 |
| Бүлек башлыгы | 27 700 | 27 700 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 25 300 | 25 300 |
| Әйдәп баручы икътисадчы | 25 300 | 25 300 |
| Әйдәп баручы белгеч, программист | 25 300 | 25 300 |
| Сатып алулар буенча белгеч | 25 300 | 25 300 |
| Кадрлар буенча белгеч | 25 000 | 25 000 |
| Бухгалтер | 24 000 | 24 000 |
| Эш башкаручы | 24 000 | 24 000 |

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмәнең 3 пунктына (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) үзгәреш кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфасы | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш бухгалтер | 25 700 | 27 000 |
| Бухгалтер | | 24 500 |

Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетларының штат расписаниесенә бухгалтер вазифасын кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының саны 3,5 меңнән артык кеше тора. Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетларында бухгалтерның вазыйфаи хезмәт хакы 22440 сум тәшкил итә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча http:/aktanysh.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе А.А.Корбангалинага йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов